Республика Татарстан
САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 декабрь 2020 ел № 409

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә пиротехника эшләнмәләрен (фейерверк күрсәтүләрен) куллануны тәртипкә салу чаралары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Пиротехника эшләнмәләрен таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында» 22.12.2009 ел, №1052 карарының 3 бүлегенә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы нигезендә, халыкның тормышын һәм сәламәтлеген саклау, муниципаль милеккә, юридик һәм физик затларның мөлкәтенә зыян китерүне булдырмау максатларында, Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районының Саба шәһәр җирлеге территориясендә пиротехник эшләнмәләр (фейерверк күрсәтү) (алга таба – фейерверк) җибәрү өчен 1 нче кушымта нигезендә мәйданчыклар билгеләү һәм (кирәк булганда) раслау.
2. Фейерверклар куллануны тыярга:
-теләсә кайсы функциональ билгеләнештәге бүлмәләрдә, биналарда һәм корылмаларда, шул исәптән әйләнә-тирә территорияне дә кертеп;
- шартлау куркынычы һәм янгын куркынычы булган объектлар, җитештерү предприятиеләре территорияләрендә, газ үткәргечләрне, югары вольтлы электр тапшыру линияләрен, вокзал, барлык төр җәмәгать транспортында, шулай ук әлеге объектлар чикләреннән 500 метрдан ким булмаганда;
- балалар, уку, дәвалау-профилактика һәм фәнни учреждениеләр янындагы территорияләрдә, шулай ук әлеге объектларның чикләреннән 50 м. ким булмаганда;
- биналар (корылмалар) фасадларының түбәләрендә, балконнарда, лоджияләрдә, сәхнә мәйданчыкларында, стадионнарда һәм башка спорт корылмаларында;
- митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре, пикетлар вакытында;
- пиртотехник эшләнмәләрне эшләп чыгаручылар тарафыннан билгеләнгән яшь чикләвенә җитмәгән затлар өчен;
- «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2013 елның 26 декабрендәге 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төнлә.

3. Саба муниципаль районының Саба шәһәр җирлеге территориясендә, ачык ут ярдәмендә, конструкция эчендә һава җылытуга нигезләнгән, идарәсе булмаган ягулык материалларыннан эшләнмәләр кертүне тыярга..

4. Әлеге карарның 1 нче кушымтасы белән билгеләнгән мәйданчыкларда фейерверкларны әзерләү һәм үткәрү вакытында, III һәм аннан югары классль пиротехника эшләнмәләрен кулланганда, куркынычлылык классы:

- фейерверк үткәрү мөмкин булган техник карарлар (шартлар) эшләнергә тиеш. Алар фейерверк әйберләре урнаштыру пунктларының билгеләмәләре төшерелгән җирлек схемасын үз эченә алырга, куркынычсыз зона чикләрен, шулай ук саклау урыннарын күрсәтеп корылмаларга кадәр куркынычсыз араны күздә тотарга тиеш;

- ул янгын куркынычсызлыгының билгеләнгән таләпләренә туры килү-килмәү турында бәяләмә һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә аккредитациясе булган теләсә кайсы оешмада фейерверк үткәрү өчен тәкъдим ителгән документларга туры килү-килмәү турында бәяләмә алынырга тиеш;

- фейерверкны оештыру һәм үткәрү мәйданчыгы әлеге карарның 2 нче кушымтасында бәян ителгән таләпләргә туры килергә тиеш.

5. Тәкъдим итәргә:

5.1. Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча күзәтчелек итү һәм профилактик эш бүлеге (алга таба – Саба һәм Теләче МР буенча МОНД һәм ПР):

- үз компетенциясе чикләрендә халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында башка каналлар буенча мәгълүмат бирүдә, шулай ук янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә пропаганда үткәрүдә катнашырга;

- гамәлдәге закон кысаларында әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән оештырылган мәйданчыкларда фейерверклар җибәрү урыннарының әзерлеген тикшерүне оештырырга.

5.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге, Росгвардиянең Саба районы буенча бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба һәм Теләче районнары буенча идарәсе һәм Саба муниципаль районы Башкарма комитеты белән үзара хезмәттәшлек кысаларында Саба муниципаль районының Саба шәһәр җирлеге территориясендә фейерверкларны санкциясез рәвештә чыгаруга юл куймау буенча кирәкле ярдәм күрсәтергә, төгәлрәк әйткәндә, хокук бозучыларга карата тикшерү материалларын Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча МОНД һәм ПР га җибәрергә.

5.3. Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге, Росгвардиянең Саба районы буенча бүлеге әлеге карарны үтәү максатларында гражданнарның һәм мөлкәтнең тормышын һәм сәламәтлеген һичшиксез яклауны тәэмин итү буенча тулы хокукый һәм оештыру чаралары күрергә тиеш.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г. Гыйлманов

Саба муниципаль районы Саба
шәһәр башкарма комитетының
16.12.2020 ел, № 409 карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Саба шәһәр җирлеге территориясендә (фейерверк күрсәтү)
пиротехника эшләнмәләрен куллану буенча мәйданчыклар**

1. “Аргамак” картодромы территориясе, адресы: Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Строителей урамы, 2б йорты.

Саба муниципаль районы Саба
шәһәр башкарма комитетының
16.12.2020 ел, № 409 карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә пиротехник эшләнмәләрдән (фейерверк күрсәтүләр) файдалану мәйданчыгына таләпләр**

1. Фейерверк үткәрү мәйданчыгы коймаланырга һәм беренчел янгын сүндерү чаралары белән җиһазландырылырга тиеш.

2. Анда куркынычсыз зона чикләрен, шулай ук эшләнмәләрне саклау урыннарын күрсәтеп, биналарга һәм корылмаларга кадәр куркынычсыз аралар булган фейерверк урнаштыру пунктлары билгеләмәләрен төшерү схемасы үтәлгән (А1 форматыннан ким булмаган схема күләме).

3. Тамашачылар җил исми торган тарафта булырга тиеш. Җил тизлеге эшләнгән схема буенча пиротехник эшләнмәләрне урнаштыру шарты белән секундына 10 метрдан да артмаска тиеш. Фейерверк үткәрү урыннарыннан биналарга һәм тамашачыларга кадәр куркынычсыз аралык кулланыла торган пиротехник эшләнмәләрнең инструкция таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

4. Мәйданчыкларда тәмәке тарту һәм ут кабызу, шулай ук пиротехник эшләнмәләрне караучысыз калдыру тыела.

5. Пиротехник эшләнмәләрне кулланганнан соң территория эшкәртелмәгән, эшләмәгән пиротехник эшләнмәләр һәм аларның куркыныч элементларыннан каралырга һәм чистартылырга тиеш.